# КАРАР

**« 05 » апрель 2024 ел N 2**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл жирлегенең Югары Курса авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 27 ноябрендәге 3 номерлы карарга үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл жирлегенең Югары Курса авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Урта Курса авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә 2024 елның 05 апрелендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Югары Курса авылында «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Югары Курса авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены мәсьәләсен яңа редакциядә бәян итү өлешендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә, түләү күләме 1200 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан, тумыштан инвалид булганнардан 600 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- һәйкәлләр кую, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасы объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга обелиск урнаштыру, территорияне төзекләндерү);
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү («Игелек» чишмәсе территориясен төзекләндерү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгын агымдагы ремонтлау)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Халык җыены беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 132 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 69 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 67 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл жирлегендә Югары Курса авылында халык җыенын булып узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

« Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә, түләү күләме 1200 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан, тумыштан инвалид булганнардан 600 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- һәйкәлләр кую, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасы объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга обелиск урнаштыру, территорияне төзекләндерү);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү («Игелек» чишмәсе территориясен төзекләндерү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгын агымдагы ремонтлау)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга кабул ителгән».

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Югары Курса авылы, Югары Курса авылы, Мәктәп урамы, 16а йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урта Курса авыл җирлеге башлыгы
Арча муниципаль районы — Вафина Р. Р.